ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 елның «12» февраленнән — № 59

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә, торак йортны бакча йорты һәм бакча йортын торак йорт дип тану буенча нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законыk, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урын, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 03 августындагы 207 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен

яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия составын кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссиясенә үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак урын, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән билгеләнгән хокукый нормалар таләпләренә таянырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында» 2023 елның 30 маендагы 138 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында

http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «12» февраленнән
59 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә бинаны торак урын, торак урынын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия составы

Ведомствоара комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Габетдинов Ренат Хәлфәт улы | - | - Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары; |

Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Кәбирова Диләрә Нәкыйп кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |

Ведомствоара комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Козлова Анастасия Николаевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге әйдәүче белгече |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Ихсанова Наилә Нариман кызы | - | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары - Түбән Кама районара торак инспекциясе башлыгы (килешү буенча) |
| Мостафина Гөлфирә Харис кызы | - | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча |

| | | |
|---|---|---|
| | | идарәсенең Чистай һәм Спас районнары территориаль бүлегенең әйдәп баручы белгеч – эксперты (килешү буенча) |
| Попкова Наталья Владимировна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - | карала торган мәсьәләгә карап |